Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге башкарма комитеты К А Р А Р Ы

2018 елның 8 ноябре 29№

Югары Колчура авыл җирлегенең 2018 елның 31 маендагы «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләргә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Югары Колчура авыл җирлеге буенча бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында»6 номерлы карарына (2018 елның 24 августындагы 10 номерлы Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге Советы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү турында (алга таба - 10 номерлы карар)

Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, Әлки районының Югары Колчура авыл җирлегенең хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган муниципаль хезмәткәрләргә, социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм хезмәт өчен түләү шартларын тәртипкә салу максатларында, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 17 октябрендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»182 номерлы карары белән расланган “Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында" 940 номерлы карары нигездә Югары Колчура авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 10 нчы Карарга түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 10 номерлы Карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлки районының Югары Колчура авыл җирлеге Советының 2009

елның 14 июлендәге "Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында" 12 номерлы карары, Әлки районының Югары Колчура авыл җирлеге Советының 2011 елның 10 маендагы 12 номерлы карары. "Әлки районының Югары Колчура авыл җирлеге Советының 2009 елның 1 июлендәге "Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында» 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

- 10 номерлы Карарның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә һәм 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла".

- Әлки муниципаль районы Югары Колчура авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 2 өлешендәге 2.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3 Авыл җирлеге башлыгына һәм аның урынбасарларына айлык акчалата түләүләр башлыкларга елына 6,72 айлык акчалата бүләкне, аларның урынбасарларына елына 8 айлык акчалата бүләкне тәшкил итә торган нормативтан артмаска тиеш.»

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль районы
Югары Колчура авыл җирлеге башлыгы: Е.В.Краснова